**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

23.12.2024 № 1558

2025 елга күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексы күләмен раслау хакында

Россия Федерациясе Торак кодексының 158 маддәсе 4 өлеше нигезендә, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 06.04.2018 №213/пр боерыгы нигезендә «Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү буенча, торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү турында, шулай ук мондый түләү күләмен үзгәртүнең иң чик индексларын билгеләү тәртибен билгеләү буенча Методик тәкъдимнәрне раслау хакында», Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТТЕ:

1. Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында Карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексын 2025 елга 4,5 процент күләмендә расларга.
2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин